# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Татар Чилчәсе торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**01 нче декабрь 2023 нче ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның «01» нче декабрендә 15 сәгать 00 минутта уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләретурында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2024 нче елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Татар Чилчәсе торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, укытуның көндезге формасында белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында һәм иректән мәхрүм итү урыннарында хезмәт итүгә чакырылган затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр контракты буенча, мобилизованныйлар) һәм аларның гаилә әгъзаларын (әти-әниләре,тормыш иптәшләрен, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итеп, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсҗәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (торак пункт урамнарын кардан чистарту, дизель ягулыгы һәм май сатып алу, килешү буенча тракторчының эшләре өчен түләү).

2. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау һәм электр энергиясен җиһазлар (электр товарлары һәм урам яктырту лампалары сатып алу) тапшыруны гамәлгә ашыру.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия жыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар жыенында катнашучы 24 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 15 кеше, бу 62,5 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар жыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар жыенында катнашкан 15 кеше тавыш бирде;

"КАРШЫ" позициясе өчен жыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар жыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Татар Чилчәсе торак пунктында гражданнар жыенын узган дип таныргa, гражданнар жыены нәтиҗәләрен - дөрес дип таныргa.

2. 2024 нче елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Татар Чилчәсе торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә житкән ялгыз өлкән гражданнардан, укытуның көндезге формасында белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында һәм иректән мәхрүм итү урыннарында хезмәт итүгә чакырылган затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр контракты буенча, мобилизованныйлар) һәм аларның гаилә әгъзаларын (әти-әниләре,тормыш иптәшләрен, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итеп, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым чаралары жыюны кертергә .

3. Түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә жибәрергә:

1. Татар Чилчәсе торак пункты чикләрендә жирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Урман урамы юлларына вак таш сатып алу һәм жәю;
- торак пункт урамнарын кардан чистарту;
- МТЗ-82 тракторы өчен май, дизель ягулыгы сатып алу;
- шартнамә буенча тракторчының эшенә түләү.

2. Татар Чилчәсе торак пункты территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:

- урамнарны яктырту өчен лампалар, фонарьлар сатып алу, аларны урнаштыру.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://agryz.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен әлеге карарны җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы М.М.Мөхәммәдиев